Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан авыл җирлеге Советы

КАРАР № 20

Олы Солтан ав. 18 нче декабрь, 2023 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы № 25-ФЗ Федераль законга тәңгәлләштереп, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Солтан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 августындагы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Олы Солтан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 7 номерлы карары;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Советының 2019 елның 2 апрелендәге «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Солтан авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешмалар белән (сәяси фиркадән гайре) бер үзе башкарма орган сыйфатында идарә итүдә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүенә рөхсәтен алу тәртибе турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 августындагы 7 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 6 номерлы карары.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Солтан авылы, Р.Шәрәфиев урамы, 12 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм

http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Сөнгатуллин